**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 елның 16 декабре. № 12

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 08.02.2019 ел, № 91 карарына үзгәрешләр кертү турында (04.04.2019 ел, № 97, 08.06.2019 ел, №100, 15.07.2019 ел, №105, 09.08.2019 ел, №107, 06.09.2019 ел, №108, 17.02.2020 ел, №122 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясенен аерым закон актларына узгэрешлэр керту турында» 2020 елнын 31 июлендэге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендэ Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Советы
**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлегендә 2019 елның 8 февралендәге 91 номерлы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Советының карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында 04.04.2019 № 97, 08.06.2019 №100, 15.07.2019 №105, 09.08.2019 №107, 06.09.2019 №108, 17.02.2020 №122) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр:

**15 статьяның 3 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« 3. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар ";

**20 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

**20 статьяның 3 пунктындагы 6 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« 6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

**34 статьяның 4 пунктына** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру.";

2. Кәкре Күл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aksubaevo.tatar.ru> Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә»

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге, Советы Рәисе С. С. Елисеев

Муниципальное образование "Аксубаевский муниципальный район" Республики Татарстан
Совет Кривоозерского сельского поселения
ИНН 1603001302 ОГРН 1021605354284